КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 март г.Казань № 240

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарын тормышка ашыру буенча чаралар хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр бирү тәртибен;

эш бирүченең документы (белешмә кәгазе) формасын;

йөк җибәрүче тарафыннан бирелә торган белешмә кәгазе формасын;

Татарстан Республикасында гамәлгә кертелгән санитария-эпидемиология һәм башка тыюлар һәм чикләүләр турындагы кисәтү хакында хәбәрнамә формасын.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

эш бирүченең документы (белешмә кәгазе) гамәлдә булуы Татарстан Республикасы территориясе буенча хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле булмаган хәрәкәт итүгә кагылмый;

гражданнарның аерым категорияләренә дарулар, азык-төлек продуктлары һәм беренчел кирәкле товарлар илткәндә волонтерларның Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә хәрәкәт итүе Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре

министрлыгы тарафыннан бирелгән документлар (белешмә кәгазьләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Идел буе транспорт прокуратурасының Татарстан транспорт прокуратурасына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан линия транспорт идарәсенә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасына авиа- һәм тимер юл транспорты белән килүче затларга Татарстан Республикасында кертелгән санитария-эпидемиология һәм башка тыюлар һәм чикләүләр турында хәбәрнамәләр тапшыруны оештыруны, шулай ук хәбәрнамәләрнең аерып бирү талоннарын җыюны һәм аларны Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклу өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә тапшыруны.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче; 2020 ел, 27 март, 223 нче; 2020 ел, 30 март, 234 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның тугызынчы абзацында «аларны сатып алучыга илтеп бирү шарты белән, шулай ук дистанцион ысул белән» сүзләрен «дистанцион ысул белән, товарларны илтеп биреп» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ нче пункт өстәргә:

«$4^1$. 2020 елның 6 апреленнән санитария-эпидемиология торышы яхшырганга кадәр дәүләт тернәкләндерү үзәкләре, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләре, шулай ук инвалидларга, 65 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга, инвалид балаларга тернәкләндерү хезмәтләре күрсәтүче бүлекләр, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган дәүләткә карамаган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр эшчәнлеген туктатырга.»;

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ нче пункт өстәргә:

«$11^1$. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге, «Гомумроссия халык фронты» төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе белән берлектә, түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

гражданнарның аерым категорияләренә дарулар, азык-төлек продуктлары һәм беренчел кирәкле товарлар илтеп бирү буенча волонтерлар эшен;

гражданнарның аерым категорияләренә дарулар, азык-төлек продуктлары һәм беренчел кирәкле товарлар илтеп бирү мәсьәләләре буенча «кайнар линияләр» телефоннары эшләвен;

волонтерларны шәхси саклану чаралары (саклагыч битлекләр, антисептиклар, перчаткалар) белән.».

5. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 31 март, 240 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр (алга таба – рөхсәтнамә) бирү механизмын җайга сала.

2. Рөхсәтнамә Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче (булучы), махсуслаштырылган сервиста теркәлүче затларга (алга таба – гражданнар) бирелә.

3. Махсуслаштырылган сервиста теркәлү өчен граждан 2590 номерына түбәндәге текст белән бушлай СМС-хәбәр җибәрә: «ТЕРКӘЛҮ#Фамилиясе Исеме Атасының исеме#паспорт сериясе һәм номеры#факттагы яшәү урыны адресы»* (мәсәлән: ТЕРКӘЛҮ#Иванов Иван Иванович#9219632506#Казан Нигматуллин 5 фатир 9).

Бу пунктта күрсәтелгән СМС-хәбәрне җибәрү шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза булу дигәнне аңлата.

4. Мәгълүмат эшкәртелгәннән соң граждан җавап бирү рәвешендә килә торган СМС-хәбәр ярдәмендә уникаль теркәлү коды ала.

5. Рөхсәтнамә алу өчен махсуслаштырылган сервиста теркәлгән граждан, түбәндәге очракларның берсен сайлап алу юлы белән хәрәкәт итү максатын күрсәтеп, 2590 номерына «МАКСАТ» тексты белән СМС-хәбәр җибәрә:

1) судта булу;

2) балигъ булмаганнарны белем бирү оешмасына (белем бирү оешмасыннан) алып бару (алып кайту);

3) медицина яки ветеринария оешмасында булу;

4) җеназаларда катнашу;

---

*Атасының исеме булганда күрсәтелә; паспортның сериясе һәм номеры пробелларсыз һәм билгеләрсез күрсәтелә; адресы буларак торак пунктның исеме, урам исеме, йорт номеры, фатир номеры күрсәтелә.

5) паспорт алу / паспортны яңадан эшләтү;

6) дачага (шәһәр читендәге йортка) бару / дачадан (шәһәр читендәге йорттан) кайту;

7) кредит оешмаларында һәм почта бүлекчәләрендә булу;

8) эшкә сәләтсез туганнарга дарулар, азык-төлек продуктлары һәм беренчел кирәкле әйберләр илтү, аларга ярдәм күрсәтү;

9) яшәү урыны (тору урыны) үзгәрү.

6. Уникаль теркәлү коды һәм аның гамәлдә булу чоры белән җавап бирү рәвешендә килә торган СМС-хәбәр алганда хәрәкәт итү рөхсәт ителгән дип санала.

7. Яшәү урыны (тору урыны) үзгәргәндә, шулай ук дачага (шәһәр читендәге йортка) бару датасы дачадан (шәһәр читендәге йорттан) кайту датасы белән туры килмәгән очракта, бу Тәртипнең 3 нче пункты нигезендә яңадан теркәлү таләп ителә.

8. Рөхсәтнамә алу түбәндәге очракларда таләп ителми:

а) ашыгыч (кичектергесез) медицина ярдәме күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә һәм тормышка һәм сәламәтлеккә башка турыдан-туры куркыныч янаган очракларда;

б) якын урнашкан, сатуы чикләнмәгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу урынына барганда;

в) яшәү урыныннан (тору урыныннан) 100 метрдан артмаган ераклыкта йорт хайваннарын урамда йөрткәндә;

г) калдыкларны якында урнашкан калдыклар җыю урынына кадәр чыгарганда;

д) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган форма буенча эш бирүченең документы (белешмә кәгазе) булганда эшчәнлеге туктатылмаган оешмада эш урынына (эш урыннан) барганда (кайтканда), мондый оешмаларда хезмәт бурычларын үтәгәндә;

е) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган форма буенча йөк җибәрүченең белешмә кәгазе булганда йөкләрне Татарстан Республикасы чикләрендә, шулай ук йөкләрне Татарстан Республикасыннан җибәрүгә бәйле рәвештә ташыганда;

ж) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан бирелгән документ (белешмә кәгазе) булганда волонтерлар гражданнарның аерым категорияләренә дарулар, азык-төлек продуктлары һәм беренчел кирәкле товарлар илткәндә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 31 март, 240 нчы
карары белән расланды

Форма

<оешма/индивидуаль эшмәкәр бланкы*>

Эш бирүченең
**БЕЛЕШМӘ КӘГАЗЕ**

Бирү датасы 2020 елның «____»_____________ № __________

Бу белешмә кәгазе _______________________________________________
*(Ф.И.Ат.ис.*, туган көне)*
_______________________________________________________________,
паспорты _______________________________________________________,
*(паспортның сериясе, номеры, бирү датасы)*
яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча теркәлү адресы: _____________
_______________________________________________________________,
фактагы яшәү адресы: ____________________________________________,
аның __________________________________________________________
*(оешма, индивидуаль эшмәкәр исеме,*
__________________________________________________ эшләве һәм
*ИНН, ОГРН)*
_______________________________________________________________
*(яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында*
_______________________________________________________________
*кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булуына кагылмый торган өлкә)*
эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында бирелде.

Эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыны: ______________________________
*(эш урынының факттагы урнашу урыны адресы*
_______________________________________________________________
*яки юлда йөреп башкарыла торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру территориясе)*

Бу мәгълүматларның дөреслеге түбәндәге телефон номеры буенча тикшерелергә мөмкин: ______________________________.

Җитәкче ________________ ____________________
(башка вәкаләтле зат) *(имзасы)* *(фамилиясе, инициаллары)*
М.У.*

________________
*Булган очракта.

____________________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 31 март, 240 нчы
карары белән расланды

Форма

< оешма/индивидуаль эшмәкәр бланкы *>

Йөк җибәрүченең

**БЕЛЕШМӘ КӘГАЗЕ**

Бирү датасы 2020 елның «____»____________ № _________

Бу белешмә кәгазе белән ________________________________________________
*(дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы,*

________________________________________________________________________
*оешма, индивидуаль эшмәкәр исеме, ИНН, ОГРН)*

________________________________________________________________ның(нең)
*(Ф.И.Ат.ис.**, туган көне, вазыйфасы)*

________________________________________________________________________,

паспорты _______________________________________________________________,
*(паспортның сериясе, номеры, бирү датасы)*

яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча теркәлү адресы: ________________________

________________________________________________________________________,

факттагы яшәү адресы:___________________________________________________,

_____________________________дан(нан) ___________________________га(ка) кадәр,
*(маршрут башлану адресы)* *(маршрут тәмамлану адресы)*

__________________________________________________________________ кереп,
*(торак пунктларның – йөк алу, илтү урыннары исемнәре)*

йөк ташуны гамәлгә ашыруынраслый*.

Йөк ташу ____________________________________________ автомобиле белән,
*(маркасы, моделе)*

транспорт чарасының дәүләт теркәү билгесе: _____________________________

______________________________________________________ гамәлгә ашырыла.

Юлга чыгу датасы _______________________ – ___________________________.
*(маршрут башлану адресы)* *(юлга чыгу датасы)*

Бу мәгълүматларның дөреслеге түбәндәге телефон номеры буенча тикшерелергә мөмкин: _________________________.

Җитәкче _______________ ____________________
(башка вәкаләтле зат) *(имзасы)* *(фамилиясе, инициаллары)*

_______________М.У.**

* Бу транспорт чарасында йөк ташуны гамәлгә ашыручы барлык затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), вазыйфалары, шулай ук паспорт мәгълүматлары, теркәлү һәм факттагы яшәү адреслары күрсәтелә.

**Булган очракта.

___________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 31 март, 240 нчы
карары белән расланды

Форма

_______________________________________________________________________________

(транспорт оешмасының исеме күрсәтелә)

**ХӘБӘРНАМӘ**

Мин, ___________________________________________________________________________________,

(пассажирның Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда), туган көне)

_______________________________________________________________________________________,

(теркәлү урыны адресы)

_______________________________________________________________________ рейс белән барып,

(рейс номеры һәм юл йөрү маршруты күрсәтелә)

2020 елның «____» ________________________________________________________ килеп җиткәч,

(килү урынының торак пункты күрсәтелә)

Россия Федерациясендә COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга бәйле рәвештә, транспорт оешмасы хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасында кертелгән санитария-эпидемиология һәм башка тыюлар һәм чикләүләр (яшәү урынын йә вакытлыча тору урынын ташлап китүне тыюны кертеп) (азык-төлек продуктлары, медикаментлар сатып алган һәм медицина ярдәме күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очраклардан һәм башка очраклардан тыш) турында, шулай ук Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турындагы кодексының 6.3 статьясы һәм башка законнар нормалары белән санитария кагыйдәләрен һәм гигиена нормативларын үтәмәгән, санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы чараларны, чикләү чараларын (карантинны) үтәмәгән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Үз-үзеңне изоляцияләү режимында булырга һәм әлеге авыру симптомнары (ютәл, тән температурасы югары булу, авыр сулау һ.б.) барлыкка килгәндә башка затлар белән элемтәгә керүне бетерү кирәклеге турында һәм, элемтә чараларын кулланып, бу турыда медицина хезмәтләренә хәбәр итү кирәклеге турында кисәтелде.

Шулай ук Татарстан Республикасы чикләрендә гамәлдә булган, вәкаләтле хакимият органнары карарлары белән билгеләнгән һәм төбәктә булучы затлар тарафыннан үтәлергә тиеш булган барлык чикләүләр һәм тыюлар турындагы мәгълүматның pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылуы турында хәбәр ителдем.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

**ЕРТЫП АЛУ ТАЛОНЫ**

Мин, ______________________________________________________________________________,

(пассажирның Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда), туган көне)

2020 елның «___» ________да(дә) Татарстан Республикасында кертелгән санитария-эпидемиология һәм башка чикләүләр (яшәү урынын (вакытлыча тору урынын) ташлап китүне тыюны кертеп), үз-үзеңне изоляцияләү режимында булу, шулай ук законнар белән билгеләнгән санитария кагыйдәләрен һәм гигиена нормативларын үтәмәгән, санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы чараларны, чикләү чараларын (карантинны) үтәмәгән өчен җаваплылык турында хәбәрнамә алдым.

2020 елның «____» _______________________ _______________________________________________

(пассажирның шәхси имзасы, аның фамилиясе, инициаллары)

Ертып алу талонын пассажирдан
алды:_________________________________________________________________________

(транспорт оешмасы хезмәткәренең фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы)

2020 елның «____» ________ _____________________________________

(транспорт оешмасы хезмәткәре имзасы)

***Игътибар! Ертып алу талоны аны алган хезмәткәр тарафыннан билгеләнгән тәртиптә саклауга тапшырылырга һәм вәкаләтле органнар сораулары буенча бирелергә тиеш***

_______________________________________________